ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22 ноябрь 2018ел № 6940

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Башкарма комитетның «Башкарма комитетның «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 16 ноябрендәге 7007 нче карары үз көчен югалткан дип тану турында» 2018 елның 11 маендагы 2601 нче карары кабул ителү сәбәпле, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карары белән (Башкарма комитетның 2016 елның 24 июнендәге 3237 нче, 2016 елның 13 декабрендәге 6675 нче, 2017 елның 8 февралендәге 588 нче, 2017 елның 3 маендагы 2747 нче, 2018 елның 18 июлендәге 4000 нче, 2018 елның 27 июлендәге 4226 нчы, 2018 елның 2 августындагы 4343 нче, 2018 елның 25 сентябрендәге 5513 нче карарлары редакциясендә) расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлегенә, 21 пунктны төшереп калдырып, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев